| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.08.2022 Баулы шәһәре №63

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Баулы шәһәр Советы карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Баулы шәһәр Советы карары проектын хупларга һәм фикер алышуга, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта)

2. 1 нче кушымта нигезендә беренче укылышта карар проектын кабул итәргә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

- Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары проекты һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашуын исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта);

- Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль

районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (3 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының http//pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1. Тимофеев Станислав Николаевич - эшче төркем рәисе.

2. Мөхәммәтшина Римма Марсель кызы - эшче төркем әгъзасы.

3. Садыйкова Гөлнара Зәкәрия кызы - эшче төркем әгъзасы.

6. Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2022 елның ________ 16:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Баулы ш., Куйбышев ур., 20, Баулы муниципаль районы Советының утырышлар залы.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча Баулы шәһәр Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы шәһәр Советы каравына чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры

вазыйфаларын башкаручы,
шәһәр Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы –
Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов

Баулы шәһәре Советының
2022 елның ____ маендагы
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Баулы шәһәр Советы карары
ПРОЕКТЫ

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8 статьяда:

бишенче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

алтынчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) эшчәнлеген булдыруны һәм тәэмин итүне кертеп,

автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл хәрәкәте оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»;

егерме икенче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлек чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру;»;

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29) җирлек территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;»;

37 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37) «Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;»;

түбәндәге эчтәлекле 41) пункт өстәргә:

«41) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм уздыру, күчемсез мөлкәтнең бердәм

дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрү.»;

17 статьядан соң түбәндәге эчтәлекле 17.1 статья өстәргә:

«17.1 статья. Инициатив проектлар

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә яисә аның өлешендә яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә хәл итү хокукы җирле үзидарә органнарына бирелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе норматив хокукый акт белән билгеләнә.

2. Инициатив проектны кертү инициативасын уналты яшькә җиткән һәм «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче кимендә ун гражданнан торган инициатив төркем, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары (алга таба - проект инициаторлары) күрсәтергә хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны Баулы шәһәр Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Проект инициаторы буларак чыгыш ясау хокукы Баулы шәһәр Советының норматив хокукый акты нигезендә шулай ук «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблема тасвирламасы;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнар исәбе;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырыла торган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәт белән катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырылган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициатив проектны гамәлгә ашыруга куллану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтү;

8) Баулы шәһәр Советының норматив хокукый акты билгеләгән тәртип нигезендә, инициатив проект гамәлгә ашырылачак «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен яисә аның чикләрен күрсәтү;

9) Баулы шәһәр Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициатив проект, аны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына керткәнче, гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә, инициатив проект турында фикер алышу, аның «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә яисә аның өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләренә туры килүен билгеләү, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатчанлыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау турында гражданнар җыелышында яисә конференциясендә каралырга тиеш. Шул ук вакытта гражданнарның бер җыелышында яисә бер конференциясендә берничә инициативалы проект каралырга мөмкин.

Баулы шәһәр Советының норматив хокукый акты белән шулай ук гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән инициатив проектны хуплау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерен ачыклау мөмкинлеге каралырга мөмкин.

Инициатив проектны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына керткәндә, проектның инициаторлары «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең яисә аның өлешенең инициатив проектын хуплавын раслый торган гражданнар җыелышы яисә конференциясе беркетмәсен, гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен һәм (яисә) имзалар кәгазьләрен беркетәләр.

5. Инициатив проектны «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат инициатив проект «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитетына кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм үз эченә әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән шулай ук проект инициаторлары турында белешмәләрне алырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнар «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына үзләренең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен, аларны тәкъдим итү срогын күрсәтеп (ул биш эш көненнән дә ким була алмый), тәкъдим итү мөмкинлеге турында хәбәр итә. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге кешеләре җибәрергә хокуклы.

6. Инициатив проект «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан аны кертүкән көннән алып 30 көн эчендә каралырга тиеш. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм аның өстендә эшне җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә дәвам итәргә;

2) инициатив проектны хуплаудан баш тартырга һәм инициатив проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кире кайтарырга.

7. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициатив проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның Россия Федерациясенең федераль законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка

норматив хокукый актлары, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы таләпләренә туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив түләүләре барлыкка килмәгәнлектән, инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс сайлавын узмаган дип тану.

8. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты проект инициаторларына инициатив проектны бергәләп эшләп бетерергә тәкъдим итәргә хокуклы, ә әлеге статьяның 7 өлешендәге 5 пунктында каралган очракта, - тиеш, шулай ук аны башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы каравына аларның компетенцияләре нигезендә карарга тәкъдим итә ала.

9. Инициатив проектларны күрсәтү, кертү, тикшерү, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе Баулы шәһәр Советы тарафыннан билгеләнә.

10. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен чыгарыла торган инициатив проектларга карата инициатив проектлар булырга тиешле белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 өлешләрендәге таләпләр кулланылмый.

11. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына берничә инициатив проект кертелгән очракта, шул исәптән эчтәлеге буенча охшаш проблемаларны тасвирлап, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проектның инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аны формалаштыру һәм эшчәнлек тәртибе Баулы шәһәр Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә. Коллегиаль орган (комиссия) составы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан төзелә. Бу очракта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санының яртысы Баулы шәһәр Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проектның инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган (комиссия) тарафыннан инициатив проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проектның инициаторлары, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче гражданнар җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициатив проектны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашыруны җәмәгать контролендә тотарга хокуклы.

14. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты инициатив проектны карау турында, инициатив проектны гамәлгә ашыруның барышы турында, шул исәптән акчаларны куллану турында, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында һәм урнаштырылырга тиеш. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турындагы хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштыру

мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат составына «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге керә торган Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.»;

46 статьяның 1 пунктында 8) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) Россия Федерациясе гражданлыгы йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы) туктатылу»;

49 статьяда:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрә һәм үткәрә, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрә.»;

3 пунктта:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру җирлекләрен һәм курортларны төзи һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль милектәге су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә;»;

4 пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итә, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшләвен тәэмин итүне дә кертеп, автомобиль транспортында, шәһәр

җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

5 пунктчаның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

6 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслый, аның предметы булып муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, саклауны, аларны торгызуны оештыра;

86 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Россия Федерациясенең илкүләм үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгели торган документларда.».

2. Уставны дәүләт теркәве өчен федераль законда билгеләнгән тәртиптә юстиция органына җибәрергә.

3. Уставны дәүләт теркәвенә алганнан соң, аңны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы шәһәре Советының
2022 елның ____ маендагы
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары проекты һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашуын исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Баулы шәһәр Советы карары проектына карата тәкъдимнәр Баулы муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча язмача кертелә: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә карар басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «ачык тыңлаулар» дигән тамга белән).

Баулы шәһәре Советының
2022 елның ____ маендагы
___ номерлы карарына
3 нче кушымта

Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба - ачык тыңлаулар) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясенә язма гаризалар тапшырган шәһәр халкы да үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнаша ала.

3. Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка шәһәрнең барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Ачык тыңлауларда муниципаль берәмлек башлыгы яисә аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариатның җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы булган ачык тыңлауларда катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артык түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларнда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртипне саклау ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә кушыла. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм җирлек Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.